РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«26» гыйнвар 2023 ел г. Альметьевск № 01

Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары нигезендә, Әлмәт районы ОСФРның Әлмәт районында Клиент хезмәтенең (бүлек хокукларында) 2023 елның 24 гыйнварындагы 51-34-09/156 номерлы мөрәҗәгате нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. 1 нче, № 2 нче кушымталар нигезендә Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 7 793,48 сум күләмендә 2023 елның 1 февраленнән гамәлгә кертергә һәм билгеләргә.
2. Әлмәт шәһәре Башкарма комитетының «Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен билгеләү турында» 2022 елның 31 гыйнварендәге 02 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2023 елның 1 февраленнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.Н. Подоваловка йөкләргә.

Шәһәр
Башкарма комитеты җитәкчесе А.Р. Исхаков

Р.05-12060/12
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА
ИНН 1644035830
КПП 164401001
ОГРН 1051605067183

Әлмәт шәһәре
Башкарма комитетының
«26» гыйнвар 2023 ел № 01
карары белән расланган
1 нче кушымта

Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча
гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| № п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 110,41 |
| 2 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 4474,78 |
| 3 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 695,19 |
| 4 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2513,1 |
| 5 | Барлыгы | 7793,48 |

Башкарма комитет җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Н. Подовалов

Әлмәт шәһәре
Башкарма комитетының
«26» гыйнвар 2023 ел № 01
карары белән расланган
2 нче кушымта

Әлмәт шәһәре территориясендә җирләү буенча
гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясе

| № п/п | Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 110,41 |
| 2 | Үлгән кешенең гәүдәсен тәрү | 2623,44 |
| 3 | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 1851,34 |
| 4 | Мәрхүмнең җәсәден (җәсәдләрен) зиратка алып бару | 695,19 |
| 5 | Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2513,1 |
| 6 | Барлыгы | 7793,48 |

Башкарма комитет җитәкчесенең
икътисад буенча урынбасары А.Н. Подовалов